ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА МАМАДЫШ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ МАМАДЫШ
ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-31-55, факс 3-17-51, e-mail: Gorod.Mam@tatar.ru, www.mamadysh..tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 28 от « 26 » январь 2024 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Мамадыш шәһәре
җирлекара күмү урыннарында
җирләү буенча гарантияләнгән исемлек
нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен
раслау турында

«Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 нче гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль законның 9 статьясының 3 пункты һәм 12 статьясының 3 пункты (үзгәрешләр һәм өстәмәләрне исәпкә алып), «Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә 8370,2 сум күләмендә билгеләргә һәм 2024 нче елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 27 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияләнгән исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен раслау турында » № 21 карарын гамәлдән чыкты дип танырга.
3. Бу карарны массакүләм мәгълүмат чараларында («Нократ ("Вятка")) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында (http://mamadysh.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга(pravo.tatarstan.ru).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р. М. Гарипов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Мамадыш шәһәре
Башкарма комитетының
26.01.2024 ел , № 28 карарына
1 нче № кушымта

2024 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре җирлекара күмү
урыннарында җирләү буенча
гарантияле исемлек нигезендә тормыш иптәше, якын туганнары, законлы
вәкиле үлгән (һәлак булган) очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда). |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,0 |
| 2. Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 3850,33 |
| 3. Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 1003,26 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3516,61 |
| Барлыгы | 8370,20 |

Татарстан  Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Мамадыш шәһәре
Башкарма комитетының
26.01.2024 ел , № 28  карарына
2 нче № кушымта

2024 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Мамадыш шәһәре җирлекара күмү урыннарында җирләү  буенча гарантияле исемлек нигезендә, тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле булмаган очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
| --- | --- |
| 1. 1.Җирләү өчен документлар әзерләү | 0,0 |
| 2. Мәетне киендерү, кәфенләү | 1194,54 |
| 3.Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 2765,12 |
| 4.Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 1023,57 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3386,97 |
| Барлыгы | 8370,20 |